**Казан шәһәре Башкарма комитетының**
**2026 елның 27 мартындагы 971 номерлы карары**

**Казан шәһәре Башкарма комитетының**
**2025 елның 18 апрелендәге 1250 номерлы**
**«Махсус хәрби операциядә катнашучы Россия Федерациясе гражданнарының балалары өчен исемле электрон юл билетлары (транспорт картасы) әзерләүгә тотылган чыгымнарны каплау максатыннан оешмаларга Казан шәһәре муниципаль берәмлеге бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен раслау турында»гы карарына үзгәреш кертү хакында**

Россия Федерациясе Бюджет кодексының 78 статьясы, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2023 елның 25 октябрендәге 1782 номерлы «Юридик затларга, шәхси эшмәкәрләргә, шулай ук товар җитештерүче, эшләр башкаручы, хезмәтләр күрсәтүче физик затларга Россия Федерациясе субъектлары бюджетларыннан, җирле бюджетлардан субсидияләр, шул исәптән субсидияләр рәвешендә грантлар бирүне һәм күрсәтелгән субсидияләрне, шул исәптән субсидияләр рәвешендәге грантлар алучыларны сайлап алуны уздыруны җайга сала торган норматив хокукый актларга, муниципаль хокукый актларга карата гомуми таләпләрне раслау турында»гы карары нигезендә **карар бирәм**:

1. Казан шәһәре Башкарма комитетының 2025 елның 18 апрелендәге 1250 номерлы «Махсус хәрби операциядә катнашучы Россия Федерациясе гражданнарының балалары өчен исемле электрон юл билетлары (транспорт картасы) әзерләүгә тотылган чыгымнарны каплау максатыннан оешмаларга Казан шәһәре муниципаль берәмлеге бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен раслау турында»гы карарына, 41 пунктында «151,43 сум» сүзләрен «200,07 сум» сүзләренә алмаштырып, үзгәреш кертергә.

2. Әлеге карар белән кертелә торган үзгәрешнең йогынтысы 2026 елның 1 мартыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.

3. Әлеге карарны «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми

мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) бастырып чыгарырга, Казан шәһәре җирле үзидарә органнарының рәсми порталында (www.kzn.ru) һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Казан шәһәре Башкарма комитеты Җитәкчесе урынбасары И.С.Шакировка йөкләргә.

**Җитәкче** **Р.Г.Гафаров**